ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 22 » апрель 2026 ел** **№ 16**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының “Белешмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2024 елның 15 ноябрендәге 25 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

”Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының “Белешмә (күчермә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2024 елның 15 ноябрендәге 25 номерлы карары белән расланган белешмә (күчермә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктындагы 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк булган очракта һәм федераль закон нигезендә мондый шәхси күрсәткечләрне эшкәртү күрсәтелгән зат ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәтне алу өчен мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә ризалыгын алуын

раслый торган өстәмә документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Сеҗе авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.В.Хамидуллин